**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**28 декабрь, 2022 ел** **№ 259**

## 2023 елга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, «Конкуренцияне яклау турында» 2006 елның 26 июлендәге 135-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләти һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фаразлау планнарын (программаларын) эшләү кагыйдәләре раслау һәм федераль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар әзерләү һәм кабул итү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2005 елның 26 декабрендәге 806 номерлы карары, «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2016 елның 3 ноябрендәге 93 номерлы карары белән расланган «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы карары белән, Биектау муниципаль районында муниципаль мөлкәтне аукционда сату тәртибен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

### КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы күчемсез мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) расларга.
2. Биектау муниципаль районы «Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесенә 2023 елга хосусыйлаштыруның фаразлау планын билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora. tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында http://pravo. tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2022 елның 28 декабрендәге 259
номерлы карары белән расланды

**2023 елга Биектау муниципаль районы**
**муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның**
**фараз планы**

## 1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыруның төп бурычлары һәм юнәлешләре

1.1. 2021 елга Биектау муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру планы (алга таба текст буенча - Хосусыйлаштыру планы) «Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Биектау муниципаль районы уставы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының 2016 елның 3 ноябрендәге 93 номерлы карары белән расланган «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәтне биләү, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып эшләнде.

1.2. 2023 елда хосусыйлаштыруның төп максатлары һәм бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

- Биектау муниципаль районының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен хәл итү һәм аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен файдаланылмый торган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштырудан җирле бюджетка салым булмаган керемнәр керүне тәэмин итү;
- эффектив булмаган мөлкәтне тотуга муниципаль район бюджетыннан чыгымнарны киметү;
- хосусыйлаштырылырга тиешле объектларны икътисадый нигезләнеп сайлау;
- муниципаль район бюджетының максималь керемен тәэмин итә торган хосусыйлаштыру ысулларын билгеләү.

1.3. Хосусыйлаштыру планын формалаштыруның төп принциплары:

- аларны арендалау җирле бюджетка тиешле акчалар керүне тәэмин итми торган объектларны хосусыйлаштыру планына кертү;
- читләштерүнең социаль-икътисадый максатчанлыгы һәм объектларның үзенчәлеген исәпкә алып, хосусыйлаштыру ысулын сайлау.

1.4. Биектау муниципаль районының муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру ысуллары һәм тәртибе Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә билгеләнә.

Хосусыйлаштыру объектларын сатуның башлангыч бәясе «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында» Федераль закон таләпләре нигезендә билгеләнгән базар бәясеннән чыгып билгеләнә.

## 2. Хосусыйлаштырылуы 2023 елда планлаштырылган муниципаль мөлкәт

2.1. 2023 елда хосусыйлаштырылырга тиешле муниципаль милек объектлары исемлеге әлеге Фараз планына кушымтада китерелгән (кушымта итеп бирелә).

2.2. Күрсәтелгән мәйданнар фаразлана һәм хосусыйлаштыруга объектны әзерләгәндә техник инвентаризация барышында төгәлләштерелергә тиеш.

Биектау муниципаль районы Советының 2022 елның 28 декабрендәге 259 номерлы карары белән расланган Биектау муниципаль районы муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планына кушымта

**2023 елга Биектау муниципаль районы**
**муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыруның фараз планы**

| № т/б | Объект исеме | Объектның урнашкан урыны | Объект мәйданы, кв.м. | Җир кишәрлегенең кадастр № | Хосусыйлаштыруның күздә тотылган срогы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Бакча җир кишәрлегендә урнашкан торак төзелеше, яшәүне теркәү хокукыннан башка, билгеләнеше: торак булмаган | Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Красносельский авыл җирлеге, Березовка СНТсы территориясе, 60 йорт | 24,2 | 16:16:221201:1067 | II квартал |
| | Җир кишәрлеге | ориентир адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районы, Красносельский авыл җирлеге, Березовка СНТсы тер., 60 ж/к | 356,0 | 16:16:221201:1039 | II квартал |